**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Югары Налим авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**26.11.2024** **№ 150**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге Советының 2018 елның 13 сентябрендәге 107 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге территориясендә транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирлекләрнең, муниципаль округларның, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы карары, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 23 маендагы 643 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Югары Налим авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советының 2018 елның 13 сентябрендәге 107 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге территориясендә транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа эчтәлегенә "җәяүлеләр һәм велосипедта йөрү шартларына характеристика» сүзләрен «велосипедчылар, җәяүлеләр һәм хәрәкәт өчен индивидуаль мобильлек чараларын кулланучы затларның хәрәкәт шартларына характеристика» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1.7 пунктта:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Велосипедчылар, җәяүлеләр һәм хәрәкәт өчен индивидуаль мобильлек чараларын кулланучы затларның хәрәкәт шартларына характеристика»;

б) бишенче абзацта икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Велосипедчыларның һәм индивидуаль мобильлек чараларын хәрәкәт итү өчен файдаланучы затларның хәрәкәте гомуми файдаланудагы юллар буйлап юл йөрү кагыйдәләре таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының «Авыл җирлекләре» рәсми сайты бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә йөклим.

Совет Рәисе Л.И.Сибгатуллин